Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16 декабрь 2019 ел №347

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины турында» 2006 елның 19 маендагы 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып, Әлмәт муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Е.Афләтунова мәгълүматын тыңлап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины турында» 2006 елның 19 маендагы 72 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 19 октябрендәге 234 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 18 номерлы, 2015 елның 29 декабрендәге 45 номерлы, 2016 елның 10 августындагы 85 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 204 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне өстәргә:

1.1. 1 нче кушымта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины» исемен бирү документларын карау комиссиясе составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә»;

1.2. 3 нче кушымта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины турында Нигезләмә»дә:

1.2.1. 1.1 пунктында «Гомуми нигезләмәләр» дигән 1 бүлектәге «10 статья» сүзләрен «11 статья» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2.2. «Ташламалар һәм мактаулы исемгә лаек булган затларга билгеләнгән игътибар билгеләре» 3 бүлегенең 3.10 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Районның җирле бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла:

- Әлмәт муниципаль районының вафат булган (һәлак булган) Мактаулы гражданинын Россия Федерациясендә билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең 10 минималь күләменнән артмаган күләмдә җирләүне һәм күмүне оештыру;

- вафат булган (һәлак булган) гражданинның туганнары мөрәҗәгате нигезендә, Россия Федерациясендә билгеләнгән 10 минималь хезмәт хакы күләменнән артмаган күләмдә вафат булган (һәлак булган) Әлмәт муниципаль районының мактаулы гражданинына кабер ташын әзерләү һәм урнаштыру».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча район Советының даими комиссиясенә (Сәлахов И.Р.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 16 декабрендәге
347 нчы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины» исемен бирү документларын карау комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| 1. Зимин Андрей Александрович | Әлмәт муниципаль районы Башлыгының даими нигездә булмаган урынбасары, комиссия рәисе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| 2. Әфләтунова Роза Егоровна | Әлмәт муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| 3. Борисов Валентин Евгеньевич | Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины |
| 4. Бочкарев Николай Афанасьевич | Әлмәт шәһәр Советы депутаты, Әлмәт шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе |
| 5. Гирфанов Марат Нил улы | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 6. Исхаков Рәсим Габбас улы | Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины, Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты |
| 7. Мусин Рамил Фатыйх улы | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Әлмәт муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясе рәисе |
| 8. Мөхәммәдиев Рөстәм Нәбиулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ генераль директоры гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| 9. Нәҗметдинова Рушания Назгат кызы | районның Иҗтимагый советы рәисе, «ТИСБИ идарә университеты»ның Әлмәт филиалы директоры (килешү буенча) |
| 10. Садчикова Леокадия Александровна | Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины |
| 11. Токарев Александр Михайлович | Әлмәт муниципаль районы Башлыгының даими нигездә булмаган урынбасары |
| 12. Туманова Галина Петровна | Кичу  авыл җирлеге башлыгы, Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты |
| 13. Хәйдәрова Нажия Мисбах кызы | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты |

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов